## Туган тел 1-4 сыйныфлар

**"Туган тел"** курсының эш программалары Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта(тулы)гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы”на, авторлар:Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова.Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 һәм “Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен үрнәк программа”га, авторлар: Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова. Казан, Мәгариф-Вакыт, 2016 нигезләнеп төзелде һәм алар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан гимназиясенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең белем бирү программасының өлеше булып тора.

Эшебезнең **максаты һәм бурычлары(**цели и задачи)– укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерү, барлык сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча да сөйләмнәрен камилләштерү; ана телен өйрәнү белән кызыксынуларын тәэмин итү; татар теленең бүлекләре буенча беренчел лингвистик мәгълүмат бирү; аралашу, лингвистик, этнокультура буенча компетенцияләрен формалаштыру, универсаль уку гамәлләрен булдыру; ана теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү.

Татар балалары программаны үзләштерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләрне өйрәнә:

– Россия Федерациясендәге телләр һәм мәдәниятләрнең күп төрле булуы турында башлангыч мәгълүмат ала, телнең милли үзаңны белдерүгә нигез булуын күзаллый;

– телнең милли-мәдәни күренеш һәм аралашу чарасы булуына төшенә, рус теленең Россия Федерациясендә дәүләт теле буларак тоткан урынын һәм аның төрле милләтләр арасында аралашу чарасы булуын аңлый;

– укучыларда телдән һәм язма сөйләмне дөрес итеп төзүгә уңай караш тәрбияләнә, алар аны шәхеснең тәрбияле булу билгесе итеп кабул итә;

– туган телдә (татар телендә) башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерә, аралашуның максат һәм бурычларыннан чыгып, тиешле тел берәмлекләреннән урынлы итеп файдалана белә;

– аралашу вакытында өйрәнелгән тел берәмлекләрен танып-белү һәм гамәли максатлардан чыгып файдалана.

Татар телләрен өйрәнү нәтиҗәсендә, башлангыч сыйныф укучылары телнең аралашу чарасы булуына төшенәләр, аны милли мәдәни күренеш буларак кабул итәләр. Укучылар телдән һәм язма формада аралашу өчен, төрле мәгълүмати чараларның мөмкинлекләреннән киңрәк файдалана белергә дә өйрәнәләр, телдәге башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерәләр.

**Дәреслекләр:**

1.Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х. Әлифба – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2016.

2. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. “Татар теле. 1 нче сыйныф укучылары өчен дәреслек” - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.

3. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Залялиева А.К. “Татар теле. 2 нче сыйныф укучылары өчен дәреслек”. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017.

4. Харисов Ф.Ф., Шакирова Г.Р., Сагдеева Р.К., Хисматов Л.К.“Татар теле. 3нче сыйныф укучылары өчен дәреслек”. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017.

5.Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. “Татар теле. 4 нче сыйныф укучылары өчен дәреслек”. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.

**Укыту планында туган тел дәресләре өчен сәгатьләр саны - 276:**

1 нче сыйныф – 66 (атнага – 2)2 нче сыйныф – 70 (атнага – 2)

3 нче сыйныф –70 (атнага – 2)4 нче сыйныф –70 (атнага – 2)

**Укыту методлары һәм технологияләр** : аңлату,әңгәмә,дәреслек , сүзлекләр белән эш;

үстерелешле укыту технологиясе; проектлар методы;шәхескә юнәлтелгән технологияләр ,

тәнкыйди фикерләү технологиясе

**Контроль формалары:**укучыларның гомуми грамоталыгын тикшерү һәм үстерү, сүзлек

байлыгын арттыру,бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү

максатыннан сүзлек, аңлатмалы, тикшерү, өйрәтү диктантлары, үзлектән эш, изложение, рәсем

буенча кыска хикәяләр, сочинениеләр